**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ КАЕНСАРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**КУКМОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ КАЕНСАР**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

Каенсар авылы

11 июнь 2024ел №17

Каенсар авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Каенсар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Каенсар авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), Каенсар авыл җирлеге Советының 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 44 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 18 260 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «12688» санын «13323» санына алыштырырга;

в) Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул биләгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

г) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 41 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.Х.Исхаков